**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы № 112 «07» сентябрь 2018 ел

Референдум уздыруны башлап җибәрү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Җирле референдум үткәрү буенча оештыру:

"Сез, 2019 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
2. торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:

Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Чубар-Абдулл авылы , Совет урамы 85 йорт авыл мәдәният йорты янында; Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Буралы авылы Октябрьская урамы, 34 йорт, авыл мәдәният йорты янында; Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мянде авылы, Ялантау урамы, 36б йорты, авыл мәдәният йорты янында

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис Н. Ә. Фәтхетдинов